**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 29 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (триммер һәм бензопила өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу (Керкәле авылы территориясендә карт агачларны кисү һәм үлән чабу өчен); МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (коры-сары һәм чүп үләннәреннән территорияләрне чаптыру)Керкәле авылы территориясендә үлән чабу, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Керкәле авылы юлларын кардан чистарту);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Керкәле авылының Изгеләр чишмәсен төзекләндерү)

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле ав., Совет ур., 95 йорт буенча административ бинада, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов